**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**2022 ел, 20 апрель** **№73**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 июлендәге 177 номерлы карары белән расланган Татарстан республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.7 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының 84 статьясындагы 1 өлеше нигезендә торак пунктларның чикләрен билгеләү, үзгәртү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Коштаулы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Коштаулы**
**авыл җирлеге Башлыгы** **Х.Ф.Сабиров**